РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Старосалмановского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге
Советы

422894, РТ, Алькеевский район, с. Старые Салманы, Клубная, 1
тел: : 8 (84346) 79-8-49

Адресы: 422894, РТ, Әлки районы, Иске Салман авылы, Клуб ур., 1
факс: 8 (84346) 79-8-49

**РЕШЕНИЕ** **Иске Салман авылы** **КАРАР**

«15» апреля 2025г. № 130

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

"Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-3РТ номерлы 25, 26 статьялары, "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советы

**Карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын 10 елга расларга (1,2 нче кушымталар ) .

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 20 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук "Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (https://alkeevskiy.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

Иске Салман авылы, Клуб урамы, 1 йорт (административ бина);
Иске Тахтала авылы, Ежевика урамы, 88а йорт ( авыл клубы).

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Муниципаль берәмлеге башлыгы
Иске Салман авыл җирлеге
Советы рәисе И.А.Ферапонтова

1 нче кушымта Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге № 130 карарына

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Бермандатлы сайлау округы № 1 | Иске Салман авылы<br>Тыкрык урамы 1, №1-16 йортлар<br>Тыкрык урамы 2, № 1-16 йортлар<br>Вахитов урамы №1-21 йортлар | 62 |
| 2 | Бермандатлы сайлау округы № 2 | Иске Салман авылы,<br>Тыкрык урамы 3, №3-11 йортлар<br>Тыкрык урамы 4, № 1-4 йортлар<br>Үзәк урамы, №-1-12 йортлар<br>Күпер урамы №1-14<br>Чокырлык урамы №1-15 йортлар<br>Таулык урамы 1 йорт | 65 |
| 3 | Бермандатлы сайлау округы № 3 | Иске Салман авылы<br>Кырый урамы № 1-17 йортлар<br>Үзәк урамы №13-33 йортлар<br>Тукай урамы №17-44 йортлар | 69 |
| 4 | Бермандатлы сайлау округы № 4 | Иске Салман авылы<br>Тукай урамы, №1-15<br>Җәлил урамы, №2-22 | 68 |
| 5 | Бермандатлы сайлау округы № 5 | Яңа Баллыкүл авылы<br>Күл урамы, №1-11<br>Кыр урамы№ 6-38 | 52 |
| 6 | Бермандатлы сайлау округы № 6 | Иске Тахтала авылы<br>Ежевика урамы, № 41-89<br>Өрәңге урамы, №20-37<br>Тирәклек урамы №12-19<br>Дуслык урамы № 7-10 | 96 |
| 7 | Бермандатлы сайлау округы № 7 | Иске Тахтала авылы<br>Окол урамы, №113-125<br>Урман урамы, №2-111<br>Дуслык урамы №1-6 | 100 |

2 нче кушымта Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге № 130 карарына

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәтләнеше

